ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 в, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристләр ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

13.11.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 02

с. Русское Макулово

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Клянчино авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 3 декабрендә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Клянчино авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Клянчино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы:

**- Клянчино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау**

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Клянчино авылы, Үзәк урамы, 26 нчы йорт адресы буенча Клянчино авыл клубы бинасында 16.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге**
**Башлыгы** **А.И. Матвеева**